СОВЕТ ЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Новая, д.9, с. Нижние Яки
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422157

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Яңа ур., 9 нче йорт, Түбән Яке авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422157

тел.(факс): (85563) 2-94-38; e-mail: Yak.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар

№ 1-5 — «12» январь 2016 ел

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы», «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Яке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең «Референдум үткәрү инициативасы турында»2015 елның 18 декабрендәге 33 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге Советының «Референдум үткәрү инициативасы турында» 2015 елның 18 декабрендәге 2-4 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге Советының 2014 елның 02 апрелендәге 2-10 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым салу чараларын җыю һәм куллану тәртибе һәм гражданнарның үзара салым салу турында нигезләмә нигезендә статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2016 елның 28 февраленә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2016 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары) булдыру һәм аларның эшләвен тәэмин итү, торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының саклануына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, шулай ук автомобиль юлларын куллану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашырту.

Түбән Яки торак пункты юлларын ремонтлау;
- Г. Тукай урамы -120 метр.
- Ирек урамы -121 метр.
Дигитли т. п.
Комлык урамы 50 м.
Таш белән сибү, грейдер белән тигезләү 58,2 мең сум
мең сум

«Әйе» «Юк»

3. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге Башлыгы Р.К.Низаметдиновка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Яке авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /Р.К.Низаметдинов /